РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.10. 2023 № 715

**«Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү оешмаларының 2024 елга норматив чыгымнарын раслау турында»**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитетының «Әтнә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 11 декабрендәге 436 номерлы карары ниргезендә, Әтнә районы башкарма комитеты карар бирә:

1. 2024 елга, кушымта итеп бирелә торган:

«Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны расларга.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов

Әтнә районы башкарма комитетының 2023 елның 11 октябрендәге 715 номерлы карары белән расланган

# НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

**«Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга**

| Гомуми белем бирү оешмасының төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә, елына норматив чыгымнар,сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 108826 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 162608 |